МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.11.2018 г.Казань № 265/2-пр

Яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын конкурс буенча сайлап алуны уздыру турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында” 2018 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карарын үтәү йөзеннән,

**БОЕРАМ:**

1. Яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын конкурс буенча сайлап алуны уздыру турындагы нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба - Министрлык) Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыкларына яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын конкурс буенча сайлап алуда катнашу өчен авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына мәгълүмат бирүдә ярдәм итәргә.
3. Министрлыкның финанслау бүлеге башлыгы М.А.Мәхмүтовка акчаларны билгеләннән лимитлар чикләрендә вакытында бирүне тәэмин итәргә.
4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Р.Р.Хәбиповка йөкләргә.

Министрның беренче урынбасары Н.Л. Титов

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2018 елның 9 ноябрендәге 265/2-пр номерлы боерыгы белән расланды

# Яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын конкурс буенча сайлап алуны уздыру турында нигезләмә

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын конкурс буенча сайлап алуны уздыру турында нигезләмә (алга таба - нигезләмә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2018 елның 26 гыйнварындагы карары нигезендә эшләнде.

Әлеге Нигезләмә яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерүгә грантлар (алга таба - грантлар) бирү тәртибен һәм шартларын, шулай ук грантлар бирүгә конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру тәртибен билгели.

1.2. Грантлар бирү максаты Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясе системасын үстерү өчен шартлар булдырудан гыйбарәт.

1.3. Әлеге Нигезләмәдә кулланылучы төп төшенчәләр:

**грант** – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты территориаль бүлекчәсендә ачылган эшкәртү буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының һәм (яисә) сату буенча авыл хуҗалыгы кооперативының шәхси счетына Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктынында каралган чараларга авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү максатларында бирелә торган акчалар;

**авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы** – авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы – авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләре тарафыннан кооперативлар әгъзалары (ассоциация әгъзалыгыннан тыш) хокукларында эшкәртү яисә сату буенча кимендә 10 авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчесен берләштерә торган, табышының кимендә 70 проценты күрсәтелгән продукцияне эшкәртү һәм сату кебек эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырудан барлыкка килә торган эшкәртү һәм (яисә) сату буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы ул (алга таба - кооператив);

**конкурс комиссиясе** – яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыныц матди-техник базасын үстерүгә грантлар бирү өчен

кооперативлар заявкаларын сайлап алу максатларында төзелгән конкурс комиссиясе;

**чыгымнар планы** - мөрәҗәгать итүче тарафыннан конкурс комиссиясе раславына тапшырылган грантны куллану юнәлешләре буенча чыгымнарның статьялап бүленгән сметасы.

1.4. Татарстан Республикасында салым исәбендә торучы һәм грантлар бирүгә сайлап алу конкурсында җиңүчеләр дип танылган кооперативлар грантлар алучылар булалар (алга таба - алучылар, мөрәҗәгать итүче, конкурс).

## 2. Сайлап алу критерийлары, грантлар бирү максатлары һәм шартлары

2.1. Грантлар алу хокукына конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча конкурс комиссиясе тарафыннан ачыкланган һәм түбәндәге критерийларга туры килә торган, эшкәртү буенча яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм сатучы авыл хуҗалыгы кооперативлары ия булалар:

кооперативның дәүләт теркәвенә алыну датасыннан конкурска заявка бирелгән датага кадәр 12 ай узмаган булырга тиеш;

кооператив авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү эшчәнлеген гамәлгә ашыра, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләре тарафыннан кооперативлар әгъзалары (ассоциация әгъзалыгыннан тыш) хокукларында эшкәртү яисә сату буенча кимендә 10 авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчесен берләштерә, табышының кимендә 70 проценты күрсәтелгән продукцияне эшкәртү һәм (яисә) сату кебек эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырудан барлыкка килә;

кооперативның авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү, эшкәртү һәм (яисә) сату күләмнәрен арттыруны күздә тотучы, үз-үзен аклау срогы биш елдан артык булмаган срокка, авыл хуҗалыгы продукциясенең гомуми күләменнән кимендә 50 проөцентын аны әзерләү һәм (яисә) сортировкалау, һәм (яисә) сую, һәм (яисә) суыту өчен кооператив әгъзаларыннан алу шарты белән нигезле бизнес-планы булу;

кооперативның матди-техник базасын үстерүгә чыгымнар планы (алга таба - Чыгымнар планы) булу;

кооператив авыл хуҗалыгы кооперативларының ревизия берлеге әгъзасы була һәм Министрлыкка ел саен үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында ревизия бәяләмәсен тапшыра.

2.2. Яңа эш башлаучы кооперативның матди-техник базасын үстерүгә грантлар Татарстан Республикасының авыл территорияләрендә кулланучылар кооперациясен булдыру һәм үстерү максатларында бирелә.

2.3. Грант түбәндәгеләр өчен бирелә:

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү һәм аларны сатуга әзерләү буенча җитештерү объектларын

төзү, реконструкцияләү яисә модернизацияләү;

авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен билгеләнгән җитештерү объектларына җайланмалар һәм техника сатып алу, аларны монтажлау, чыгарыла (җитештерелә һәм эшкәртелә) торган продукциянең сыйфатына һәм иминлегенә җитештерү контроле һәм ветеринария-санитария экспертизасы лабораторияләрен җиһазлау (авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатына лаборатор анализ ясау өчен җайланмалар сатып алу);

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын транспортировкалау һәм аларны ташыганда һәм сатканда аларның сакланышын тәэмин итү өчен махсус транспорт, фургоннар, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, контейнерлар сатып алу;

авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен җайланмалар һәм техник чаралар лизингы шартнамәләре буенча взносларның бер өлешен түләү (лизинг әйберләренең гомуми хакыннан 8 проценттан да артык булмаган күләмдә).

2.4. Грант түбәндәге шартларны үтәгәндә бирелә:

2.4.1. Кооперативлар грант бирү турында шартнамә төзү планлаштырыла торган датага кадәр 15 эш көненнән дә узмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыралар;

бетерү, банкротлык процессында түгел;

әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар алучылар түгел;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне кайтару буенча түләнми калган бурычлары һәм шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты каршында башка түләнми калган бурычлары юк;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк;

2.4.2. Грантлар бирүгә заявкаларны конкурс буенча сайлап алуда җиңүче дип танылу;

2.4.3. Кооператив Чыгымнар планындагы сатып алына торган мөлкәтнең, башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең кимендә 10 процентын үз акчалары исәбеннән түли;

2.4.4. Кооператив матди-техник базасын үстерүгә үз счетына акчалар кергән датадан 24 ай эчендә грантны бары тик әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында күрсәтелгән максатларга тотарга гына йөкләмә ала.

2.5. Грант акчаларына алына торган мөлкәт кооперативның бүленми торган фондына кертелә һәм сатылмый, бүләк ителми, арендага

тапшырылмый, алыштырылмый яисә пай, кертем рәвешендә взнос итеп кертелми йә Рәссия Федерациясе законнары нигезендә башкача читләштерелми.

## 3. Конкурс уздыру тәртибе

3.1. Конкурста катнашу өчен Министрлык тарафыннан билгеләнгән срокка түбәндәге документлар тапшырылырга тиеш:

3.1.1. Кооперативның матди-техник базасын үстерүгә грант алу өчен конкурста катнашуга заявка (алга таба – заявка) – әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтадагы форма буенча;

3.1.2. . Кооператив уставыныц күчермәсе;

3.1.3. Әлеге Нигезләмәнең 2.4. пунктындагы икенче абзацында каралган максатларга грант алу өчен мөрәҗәгать иткәндә түбәндәгеләр тапшырылырга тиеш:

дәүләт экспертизасы узган проект-смета документациясенең күчермәсе, локаль сметалар һәм схема-сызымнар белән (эшләр башкарыласы урыннан фото, объект булганда – аныц тышкы һәм эчке якларыннан фотолар), аңа үз-үзен җайга салучы оешманың проектлауга рохсәт күчермәсе өстәлә (грантны төзелеш яисә реконструкцияләү өчен кулланганда);

төзелешкә (реконструкцияләүгә) һәм (яисә) эксплуатациягә тапшыруга рөхсәт (грантны төзелеш яисә реконструкцияләү өчен кулланганда);

төлеш-монтаж эшләрен башкаруга подряд оешмаларын җәлеп иткәндә яисә хуҗалык ысулы белән башкарганда алдан төзелгән шартнамәләрнең күчермәләре;

3.1.4. Әлеге Нигезләмәнең 2.4. пунктындагы оченче абзацында каралган максатларга грант алу очен мөрәҗәгать иткәндә түбәндәгеләр тапшырылырга тиеш:

җайланмалар һәм техника сатып алуга алдан төзелгән шартнамәләрнең күчермәләре;

монтажлау эшләрен башкаруга подряд оешмаларны җәлеп иткәндә төзелгән шартнамәләрнең күчермәләре;

3.1.5. Әлеге Нигезләмәнең 2.4. пунктындагы дүртенче абзацында каралган максатларга грант алу өчен мөрәҗәгать иткәндә түбәндәгеләр тапшырылырга тиеш:

транспорт чаралары сатып алуга алдан төзелгән шартнамәнең күчермәсе;

3.1.6. Әлеге Нигезләмәнең 2.4. пунктындагы бишенче абзацында каралган максатларга грант алу өчен мөрәҗәгать иткәндә түбәндәгеләр тапшырылырга тиеш:

җайланмалар һәм техника чаралары лизингы шартнамәләренең күчермәләре;

3.1.7. Бизнес-план;

3.1.8. Кооперативның кредит оешмасында ачылган счетыннан аның бүленми торган фондының счетында чыгымнарының грант акчалары исәбеннән финанслаша торган һәр статьясы суммасыннан кимендә 10 процент күләмендә үз акчалары булуын раслый торган документтан өземтә;

3.1.9. Кооперативта булган күчемсез мөлкәт объектларына хокуклар турында Күчемсез мөлкәтнең дәүләт реестрыннан алынган, вәкаләтле орган тарафыннан таныкланган һәм конкурска заявка бирү көненә кадәр 30 көннән дә алданрак булмаган вакытта бирелгән өземтәләр күчермәләре (алар булса);

3.1.10. Кооперативның матди-техник базасын үстерүгә Чыгымнар планы проекты, әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтадагы форма буенча;

3.1.11. Әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтадагы форма нигезендә шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык;

3.1.12. Мөрәҗәгать итүченең әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтадагы форма буенча анкетасы;

3.1.13. Кооперативның урнашкан урыны буенча салым органында исәпкә куелуы турында таныклыкның яисә язманың үз инициативасы белән бирелгән күчермәсе, салым органыннан кооперативның Россия Федерациясе салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, проңентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган белешмә (КНД 1120101 буенча Код формасы);

Кооператив бу документларны үз инициативасы белән тапшырмаган очракта, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә соратып ала.

3.1.14. Кооперативның ревизия берлегендә әгъза булуын раслый торган, ревизия берлеге җитәкчесе тарафыннан имзаланган һәм ревизия берлеге мөһере белән беркетелгән (мөһере булса) белешмә;

3.1.15. Булган очракта - узган календарь елы өчен бухгалтерлык (финанс) хисабы күчермәсе, аны кабул итү турында салым органы тамгасы белән, йә, хисап электрон рәвештә бирелгән очракта, гомуми (махсус) салым салу режимын кулланучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары өчен - кабул итү турындагы квитанция белән;

3.1.16. Гранттан файдалану шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәргә ризалык бирү турында кооператив әгъзаларының гомуми җыелышыннан кооператив рәисе тарафыннан таныклаган һәм кооператив мөһере белән беркетелгән карар күчермәсе;

3.1.17. Кооператив рәисе тарафыннан имзаланган һәм кооператив мөһере белән беркетелгән (мөһере булса) кооператив әгъзалары исемлеге;

3.1.18. Кооператив вәкиленең шәхесен раслый торган документ күчермәсе.

3.1.19. Кооператив вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ күчермәсе.

3.2. Таныкланырга тиешле һәм берничә биттән торучы документлар тапшырганда, аларның һәр бите таныклана. Документларның оригиналлары проектны яклаганда конкурс комиссиясе тарафыннан күчермәләрне чагыштыру өчен тапшырыла.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1 бүлегендә күрсәтелгән документлар тегелгән, номерланган, вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган һәм кооператив мөһере белән беркетелгән (мөһере булса) булырга тиеш. Мөһер белән беркетелгән (мөһере булса) һәм вәкаләтле зат имзасы белән таныкланган (юридик затлар өчен) яисә үз кулы белән таныкланган (кооператив рәисе өчен) төзәтүләрдән

тыш, чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1 бүлегендә күрсәтелгән документлар сайлап алу конкурсы уздыру турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән срокларда һәм адрес буенча тапшырыла.

Грант бирү тәртибе һәм документлар формалары турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында: http: //agro.tatarstan.ru/ – «Фермерларга, авыл хуҗалыгы кооперативларына грантлар һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр» бүлегендә, алга таба – «Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү» бүлекчәсе (алга таба - Министрлыкның рәсми сайты) урнаштырыла.

Мөрәҗәгать итүче үз заявкасын конкурсның теләсә кайсы этабында кире алырга хокуклы. Кире алу өчен кооператив җитәкчесе конкурс комиссиясенә гариза яза.

Сайлап алу конкурсын узган катнашучы әлеге Нигезләмәгә 11 кушымта формасы буенча билгеләнгән үрнәктәге сертификат ала.

## 4. Заявкалар кабул итү һәм теркәү

4.1. Грантлар бирү буенча конкурста катнашуга заявкалар кабул итү башлану һәм тәмамлану турындагы белдерү Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

Белдерүдә конкурс уздыруның урыны һәм вакыты (кимендә 30 календарь көн кала), элемтә телефоннары, Министрлык сайтының конкурс шартлары турында, заявкалар бирү һәм норматив хокукый документлар белән танышу тәртибе турында мәгълүмат урнаштырыла торган бүлеге күрсәтелә.

4.2. Заявкалар кабул итә башлау срогы белдерү басылып чыккан көннән соң килүче көн була. Белдерүдә күрсәтелгән срок узгач кооперативлардан заявкалар кабул ителми.

Алынган заявкалар һәм документлар керү тәртибендә заявкаларны теркәү кенәгәсендә теркәлә, ул номерланган, тепләнгән һәм конкурс комиссиясе секретареның имзасы таныкланган һәм Министрлык мөһере белән беркетелгән булырга тиеш. Теркәгәндә заявкага керү номеры бирелә.

4.3. Конкурс заявкасы Министрлыкка ябык конвертта кәгазьдә килеш тапшырыла. Конвертта кооперативның исеме һәм адресы, бизнес-план юнәлеше күрсәтелә.

Кооператив тарафыннан конкурска тапшырылган документлар кире кайтарылмый.

4.4. Конкурс заявкасын әзерләү буенча барлык чыгымнарны кооператив тота.

4.5. Министрлык конкурска документлар кабул итү тәмамланган көннән 5 эш көне эчендә документларны конкурс комиссиясенә җибәрә.

## 5. Конкурс комиссиясенең функцияләре һәм бурычлары

5.1. Конкурс комиссиясе үз эшчәнлегендә законнарга, әлеге Нигезләмәгә

таяна һәм үз эшен авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләренә дәүләт ярдәме инфраструктурасын тәшкил итүче оешмалар, иҗтимагый оешмалар һәм кооперативлар белән хезмәттәшлектә оештыра.

5.2. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары түбәндәгеләр була:

кооперативларның матди-техник базасын үстерүгә грант алу өчен мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан тапшырылган конкурс документациясен вакытында, ачык һәм объектив карауны тәэмин итү;

проектларның тулылыгын һәм дөреслеген, икътисадый нәтиҗәлелеген, Татарстан Республикасы икътисады өчен социаль әһәмиятлелеген һәм аңа дәүләт ярдәме күрсәтүнең максатка ярашлы булуын билгеләү өчен аларга экспертиза уздыру;

конкурста җиңүчеләрне һәм аларга бирелә торган грантлар күләмнәрен билгеләү.

5.3. Конкурс комиссиясе Министрлык боерыгы белән кимендә 12 кешедән оештырыла һәм аның составына конкурс комиссиясенең рәисе, рәис урынбасары, конкурс комиссиясе әгъзалары һәм секретаре (тавыш бирү хокукына ия түгел) керә. Конкурс комиссиясе составына дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр, авыл хуҗалыгы өлкәсендә иҗтимагый оешмалар, берлекләр, берләшмәләр һәм белем бирү оешмалары вәкилләре керә. Конкурс комиссиясе составында дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр саны – 50 проценттан кимрәк.

Конкурс нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынучы затлар (шул исәптән конкурста катнашуга гариза биргән йә бу заявкаларны биргән кооперативларда торучы затлар) йә конкурста катнашучылар тәэсир итәргә мөмкин булган затлар комиссия әгъзалары була алмый.

5.4. Конкурс комиссиясенең эше аның утырышларында башкарыла. Утырышта конкурс комиссиясе әгъзалары саныннан яртысыннан күбрәге катнашса, ул вәкаләтле дип санала.

5.5. Конкурс комиссиясе рәисе түбәндәге функцияләрне башкара:

конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аңа йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була;

конкурс комиссиясе әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә;

конкурс комиссиясе утырышларын алып бара, конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен әзерләүне һәм конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларның үтәлүен тикшереп тора.

5.6. Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, утырышта конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын үти.

5.7. Конкурс комиссиясе әгъзалары:

конкурс заявкалары белән конвертларны ачалар;

әлеге Нигезләмәдә каралган документларның булуын тикшерәләр;

кооперативның һәм тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерәләр;

баллар санын исәплиләр, аларны бәяләү ведомостена кертәләр.

5.8. Конкурс комиссиясе секретаре түбәндәге функцияләрне башкара:

конкурс комиссиясе утырышында карау өчен материаллар җыя һәм аларның саклануын оештыра;

конкурс комиссиясе утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә.

5.9. Конкурс комиссиясе, заявкалар кабул итү тәмамланган вакыттан 14 эш көненнән дә соңга калмыйча, конкурс комиссиясе утырышын уздыра, мөрәҗәгать итүчеләрнең тапшырылган документларын карый, кооперативларга грантлар бирү йә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, ул конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе (алга таба – беркетмә) итеп рәсмиләштерелә.

заявкалар кабул итү тәмамланганнан соң 10 көн эчендә конкурс комиссиясе утырышын оештыра, мөрәҗәгать итүчеләрне очрашып сөйләшү өчен утырышка чакыра.

Очрашып сөйләшү барышында конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы заявкалардагы мәгълүмат һәм бирелгән сорауларга мөрәҗәгать итүченең җаваплары нигезендә тиешле карарны кабул итә һәм һәр кооперативка карата тавыш бирү кәгазенә язып куя, шунда ук бирелә торган грант күләмен күрсәтә.

5.10. Конкурс комиссиясенең карары, аның составының яртысыннан артыгы булганда, гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Конкурс комиссиясе секретаренең сайлау хокукы юк.

Билгеләнгән критерийлар нигезендә бертигез баллар алган берничә дәгъвачы булганда, мөрәҗәгать итүчеләрнең санлы составы буенча грантлар саны фактта җитәрлек булмаса, грант «Конкурска заявкалар теркәүнең 1 нче номерлы журналы»нда заявкасы алданрак вакытта теркәлгән мөрәҗәгать итүчегә бирелә.

Тавыш бирү кәгазьләрендә конкурс комиссиясе әгъзалары белдергән карарлар нигезендә секретарь конкурс бюллетенен төзи. Тавыш бирү кәгазьләре һәм конкурс бюллетене беркетмәгә кушыла.

5.11. Конкурс комиссиясе утырышлары кирәк саен уздырыла. Конкурс комиссиясе әгъзалары утырышка рәис хәл итүе буенча чакырыла.

5.12. Конкурс комиссиясе мөрәҗәгать итүчеләр тапшырган документларны анализлау нигезендә, түбәндәге критерийларга таянып, конкурста җиңүчеләрне билгели:

| т/с № | Критерий исеме | Күрсәткечләр | Балларда бәяләү |
|---|---|---|---|
| 1 | Мөрәҗәгать итүченең милкендә һәм (яисә) кимендә 5 елга озак сроклы арендада җитештерү объектлары булу | юк | 0 |
| | | 300 квадрат метрга кадәр | 5 |
| | | 300 квадрат метрдан югары | 10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Җитештерү объектын төзү яисә реконструкцияләү өчен җир кишәрлеге булу | милек | 10 |
| | | 5 һәм аннан күбрәк елга аренда | 5 |
| 3 | Кооператив теркәлгән датадан аның акчалата кереме булу | юк | 0 |
| | | бар | 10 |
| 4 | Һәр 2,5 млн. сум грант күләменә эш урыннары булдыру | 2 | 5 |
| | | 3 һәм аннан күбрәк | 10 |
| 5 | Бизнес-план нигезендә үзен аклау срогы | 3 елдан күбрәк | 0 |
| | | 2 елдан 3 елга кадәр | 5 |
| | | 2 елга кадәр | 10 |
| 6 | Матди-техник базаны үстерүгә чыгымнар планыннан үз акчалары күләме | 11-20% | 5 |
| | | 20 %тан күбрәк | 10 |
| 7 | Кооператив әгъзалары саны | 11-15 әгъза | 5 |
| | | 15 әгъзадан күбрәк | 10 |
| 8 | Кооператив җитәкчесенең эшлекле сыйфатларын бәяләү, профессионализм, социаль һәм бюджет җаваплылыгы | иң югары балл – 10 | |

5.13. Баллар бары тик тегелгән документлар буенча гына исәпләнә, конкурс комиссиясе утырышына тапшырылган документлар балл суммасына кертелми. Иң күп җыелган баллар 80гә тиң. Конкурс комиссиясе тарафыннан уңай карар чыгару очен 25 балл җыярга кирәк. Иң күп баллар җыйган мөрәҗәгать итүчеләр сайлап алу конкурсында җиңүчеләр булалар.

5.14. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 3.1, 3.2 пунктларында күрсәтелгән документлар пакеты тулысынча тапшырылмаган, белешмәләр, исәп-хисаплар туры килмәгән очракта, конкурс комиссиясе мөрәҗәгать итүченең гаризасын очрашып сөйләшкәндә кире кага.

5.15. Грант бирүдән баш тартуга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, агымдагы ел дәвамында шикаять бирелә.

5.16. Конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләре утырыш узган көннән 5 көн эш көне эчендә аның рәисе тарафыннан раслана һәм расланганнан соң 10 эш көне эчендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

5.17. Конкурс комиссиясе секретаре конкурс тәмамланганнан соң 30 эш көне эчендә конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителгән барлык заявкаларны һәм документларны Министрлык архивына саклауга тапшыра.

5.18. Конкурска бирелгән заявкалар саны яисә грантлар откан кооперативлар саны финансланган кооперативлар санынан кимрәк булган очракта, Министрлык о с т ә м ә конкурс игълан итә, ул әлеге Нигезләмә тәртибендә уздырыла.

## 6. Грант бирү тәртибе

6.1. Документлар теркәлгән датадан соң 5 эш көне эчендә Министрлык кергән документларны тикшерә һәм чыгымнар планын, исәп-хисап белешмәсен имзалый һәм шартнамә төзи.

6.2. Министрлык Татарстан Республикасы бюджет акчаларын төп бүлүче була, акчаларны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган үзенең шәхси счетыннан 5 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль бүлекчәләрендә ачылган Татарстан Республикасы муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең (алга таба - Идарә) шәхси счетларына күчерә. Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча алучылар кысаларында Татарстан Республикасы муниципаль районына тиешле грантлар турында җыелма белешмә-исәп-хисаплар һәм шартнамәләр Идарәгә акчалар күчерү өчен нигез була.

6.3. Идарә грантларны, үзенең шәхси счетына грантлар кергән көннән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча, кооперативларның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль бүлекчәләрендә ачылган шәхси счетларына күчерә.

6.4. Грант, Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау лимитларын исәпкә алып, бирелә. Агымдагы елда грант алуга конкурс узган заявкаларны канәгатьләндерү өчен бюджет акчалары җитәрлек булмаган очракта, аларны финанслау әлеге Нигезләмә нигезендә иң күп баллар саны буенча чиратлылык тәртибендә башкарыла.

## 7. Хисап бирү рәвешләре һәм тәртибе

7.1. Чыгымнар планы нигезендә грант акчаларын һәм үз акчаларын тотып бетергәннән соң, кооператив җитәкчесе әлеге Нигезләмәгә 9 нчы кушымта нигезендә Идарә башлыгы тарафыннан расланган «Җыелма реестр»ны, акчаларның кооператив тарафыннан вакытында һәм максатчан кулланылуын раслый торган хисап-финанс документларын (грант акчаларының тотылышын раслый торган исәп-хисап счетыннан банк өземтәсе, сату-алу шартнамәләре, түләү йөкләмәләре, накладнойлар, счет-фактуралар, фото) тапшырырга тиеш.

7.2. Кооперативлар грантны алган көннән 24 ай эчендә Министрлыкка грантларны максатчан куллану турында әлеге Нигезләмәгә 10 нчы кушымтадагы форма буенча йомгаклау хисабын тапшыралар.

7.3. Грантны үзләштереп бетергәннән соң кооператив 5 ел дәвамында ел саен Министрлыкка ирешелгән күрсәткеч нәтиҗәләре турында еллык хисап әзерли. Хисап Идарәләргә хисап чоры узганнан соң 10 эш көне эчендә Министрлык боерыгы белән расланган формалар буенча тапшырыла. Идарәләр хисаплар кергәннән соң 10 эш көне эчендә аларны килештерәләр һәм Министрлыкка җибәрәләр.

Хисаплар имза һәм кооператив мөһере (булса) белән таныкланырга тиеш.

7.4. Кооператив тарафыннан хисап вакытында тапшырылмаса, Идарә

законнар нигезендә дәүләт ярдәме чараларын бирүне туктатып тора.

7.5. Алучы, хисап чорыннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, әлеге Нигезләмәнең 10 нчы кушымтасы формасы буенча эшчәнлек турында белешмәләрне тапшырырга тиеш.

## 8. Грантны куллануны тикшереп тору һәм кире кайтару тәртибе

8.1. Бирелгән грантлар, Татарстан Республикасы бюджетына бюджет законнары нигезендә кире кайтару Министрлыктан тиешле таләп алганнан соң 60 эш көне эчендә түбәндәге очракларда башкарыла: аларны бирүнең әлеге Нигезләмәдә һәм шартнамәдә билгеләнгән тәртибе һәм шартлары бозылу фактлары ачыкланса, конкурска дорес булмаган белешмәләр һәм документлар бирелгән булса, хисап тапшырылмаса, грант акчалары максатчан кулланылмаса, шулай ук грантлар белән нәтиҗәле күрсәткечләргә ирешелмәгән һәм максатчан күрсәткечләр бозылган очракта.

8.2. Шартнамәдә каралган очракларда, грантның 24 ай эчендә кулланылмый калган өлеше әлеге срок узгач 30 эш көне эчендә кооператив тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

8.3. Әлеге Нигезләмәнең 8.1 һәм 8.2 пунктларында күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджетына ихтыярый рәвештә кайтарудан баш тарткан очракта, алар законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә алынырга тиеш.

8.4. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары грантлар бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең кооперативлар тарафыннан үтәлешенә грант бирелгән датадан 12 айдан да соңга калмыйча законнар нигезендә тикшерү уздыралар.

8.5. Белешмәләрнең дөреслеге һәм тапшырылган документларның төп нөсхәләрдә булуы өчен җаваплылык кооператив җитәкчесенә йөкләнә.

8.6. Грантларның максатчан кулланылуын тикшереп торуны Министрлык башкара.

Яңа эш башлаучы
авыл хуҗалыгы кулланучылар
кооперативларын конкурс
буенча сайлап алуны
уздыру турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы авыл
хуҗалыгы һәм азык- төлек
министры урынбасары, конкурс
комиссиясе рәисе
Р.Р.Хәбиповка

______________________________

______________________________
(кооператив житәкчесенең фамилиясе, исеме,
атасының исеме, адресы)

**20____елда Татарстан Республикасы ______________ муниципаль районы ___________________яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының матди-техник базасын үстерүгә грант алу конкурсында катнашуга**

**Заявка**

________________________________________________________________________
*(Татарстан Республикасы муниципаль районы, авыл җирлеге исеме)*

________________________________________________________________________
*(авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының исеме)*

________________________________________________________________________
*(авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

20____елда Татарстан Республикасы ______________ муниципаль районы ___________________яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының матди-техник базасын үстерүгә грант алу конкурсында катнашуга кертүегезне сорыйм.

Түбәндәгеләрне раслыйм:

1. Кооператив бетерү, банкротлык процессында түгел;

2. Кооператив Нигезләмәдә күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар алучы түгел;

3. Кооперативның Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне кайтару буенча түләнми калган бурычлары һәм шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты каршында башка түләнми калган бурычлары юк;

4. Кооперативның Россия Федерациясе салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк;

5. Конкурста катнашу шартлары белән таныштым һәм риза.

Документларда һәм аларның күчермәләрендә бирелгән барлык мәгълүмат дөрес һәм мин грант бирүгә документларны карауда катнашучы затларның аларны карауларына каршы түгел.

Авыл хуҗалыгы кулланучылар
кооперативы җитәкчесе ___________ ________________

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

М.У. (булса)

“ ” 20 ел

Яңа эш башлаучы
авыл хуҗалыгы кулланучылар
кооперативларын конкурс
буенча сайлап алуны
уздыру турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Форма

**Яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының матди-техник базасын үстерүгә чыгымнар планы проекты**

____________________________________________
(кооператив исеме, район, эшчәнлек юнәлеше)

| т/с № | Чыгымнар статьясы исеме * | Сатып алынган әйберләр исеме | Саны | Бәясе | Финанслау чыганаклары, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Барысы | шул исәптән | |
| | | | | | | грант, 90 процент | үз акчалары (10 процент һәм аннан күбрәк) |
| 1 | Җитештерү объектларын төзү, реконструкцияләү яисә модернизацияләү | | | | | | |
| | Статья буенча барысы: | * | * | * | | | |
| 2 | Җитештерү биналары, корылмалар, биналар һәм цехлар өчен җайланмалар, техника сатып алу һәм монтажлау | | | | | | |
| | Статья буенча барысы: | * | * | * | | | |
| 3 | Махсуслаштырылган транспорт, фургоннар, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, контейнерлар сатып алу | | | | | | |
| | Статья буенча барысы: | * | * | * | | | |
| 4 | Җайланмалар һәм техник чаралар лизингы шартнамәләре буенча взносларның бер өлешен түләү | | | | | | |
| | Статья буенча барысы: | * | * | * | | | |
| | **Барлык чыгымнар:** | * | * | * | | | |

* Грант сорала торган юнәлешләр генә кертелә.

Кооператив җитәкчесе ________________________ «____» _________20 __ ел

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, имзасы)

МУ (булса)

Яңа эш башлаучы
авыл хуҗалыгы кулланучылар
кооперативларын конкурс
буенча сайлап алуны
уздыру турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

Форма

**Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә**
**РИЗАЛЫК**

Мин,______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме атасының исеме, вазыйфасы)
________________________ _________ № ____________, _________________________
(шәхесне таныклаучы документ, кайда, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
______________________________________________________________________
теркәлгән адресы: _______________________________________________________
______________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Оператор) ( 420014, Казан шәһәре, Федосеев ур., 36 йорт адресы буенча урнашкан), үземнең шәхси белешмәләрне түбәндәге шартларда эшкәртүгә ризалык бирәм:

1. Оператор минем шәхси белешмәләрне һәм кооператив әгъзаларының шәхси белешмәләрен эшкәртүне гамәлгә ашыра.

2. Операторга эшкәртүгә тапшырыла торган шәхси белешмәләр исемлеге:

фамилиям, исемем, атам исеме, вазыйфам, туган көнем, паспорт белешмәләре, элемтә өчен телефон (өй, мобиль, эш), фактта яшәү һәм теркәлү адресы, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы урнашкан адрес.

3.Үземнең шәхси белешмәләрне һәм кооператив әгъзаларының шәхси белешмәләрен Оператор тарафыннан эшкәртүгә, ягъни, шул исәптән, түбәндәге гамәлләрне башкарырга ризалык бирәм: эшкәртүгә (җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), файдалануны, исемсез калдыруны, блокировкалауны, шәхси белешмәләрне юкка чыгаруны кертеп), белешмәләрне эшкәртүнең югарыда күрсәтелгән ысулларының гомуми тасвирламасы «Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда китерелгән, шулай ук законнарда билгеләнгән очракларда шундый мәгълүматны өченче затларга тапшыруга ризалык бирәм.

4. Әлеге ризалык ул имзаланган датадан җиде ел буена гамәлдә була.

«Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре белән танышканымны, шәхси белешмәләрне яклау өлкәсендәге хокукларның һәм бурычларның миңа аңлатылуын раслыйм.

«___» __________20__ел ____________ ____________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

МУ (булса)

Яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын конкурс буенча сайлап алуны уздыру турында нигезләмәгә 4 нче кушымта

Форма

**Катнашучы анкетасы**

ТР_______________________________ муниципаль районы

______________________________________________________
(кооперативның исеме)

| т/с № | Күрсәткеч исеме | Мөрәҗәгать итүче белешмәләре |
|---|---|---|
| 1 | Кооперативның исеме | |
| 2 | Кооператив җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, билгеләп кую датасы | |
| 3 | Кооперативның ИНН | |
| 4 | Урнашкан урынының адресы: | |
| 5 | Кооператив әгъзалары саны, барысы: | |
| | шулардан авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләр: | |
| 6 | Кооператив дәүләт теркәвенә алынган урын (урнашкан урынының адресы) | |
| 7 | Теркәлү адресы: | |
| 8 | Хезмәткәрләр саны, барысы: | |
| | шулардан: 1) - гамәлгә куючылар: | |
| | 2) - даими эшләүче хезмәткәрләр (конкурста катнашканга кадәр кооперативта эшләүчеләр): | |
| 9 | Ревизия берлегендә катнашу (берлекнең исеме һәм урнашкан урыны) | |
| 10 | Сезонлы (вакытлыча) эшләүче хезмәткәрләр: | |
| 11 | Кооперативның элемтә телефоннары | |
| 12 | Кооператив әгъзаларының социаль категориясе (инвалид, инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналар, күпбалалы гаиләләр, элеккеге хәрби хезмәткәр, белем бирү учреждениесен тәмамлап чыгучы): | |

Кооператив җитәкчесе ___________ ____________________ ______
(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

«___» __________20__ел

Мөһер урыны (булса)

Яңа эш башлаучы авыл
хуҗалыгы кулланучылар
кооперативларын конкурс
буенча сайлап алуны уздыру
турында нигезләмәгә
5 нче кушымта

Форма

_______________________________________________ документлар
(район һәм кооператив исеме)

ИСЕМЛЕГЕ №____

Бит №

1. ____________________________________________ ___ бит, ______
2. ____________________________________________ ___ бит, ______
3. ____________________________________________ ___ бит, ______
4. ____________________________________________ ___ бит, ______
5. ____________________________________________ ___ бит, ______
6. ____________________________________________ ___ бит, ______
7. ____________________________________________ ___ бит, ______
8. ____________________________________________ ___ бит, ______
9. ____________________________________________ ___ бит, ______
10. ____________________________________________ ___ бит, ______
11. ____________________________________________ ___ бит, ______
12. ____________________________________________ ___ бит, ______
13. ____________________________________________ ___ бит, ______
14. ____________________________________________ ___ бит, ______
15. ____________________________________________ ___ бит, ______
16. ____________________________________________ ___ бит, ______
17. ____________________________________________ ___ бит, ______
18. ____________________________________________ ___ бит, ______
19. ____________________________________________ ___ бит, ______
20. ____________________________________________ ___ бит, ______
21. ____________________________________________ ___ бит, ______
22. ____________________________________________ ___ бит, ______
23. ____________________________________________ ___ бит, ______
24. ____________________________________________ ___ бит, ______
25. ____________________________________________ ___ бит, ______

Документларны тапшырды :

______________________________

______________________________

(кооператив җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Документларны алды:

______________________________

______________________________

(Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________________
(имза)

«___» __________20__ ел

______________________________
(имза)

«____»_________20__ел

Мөһер урыны (булса)

Яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын конкурс буенча сайлап алуны уздыру турында нигезләмәгә
6 нчы кушымта

| | | |
|---|---|---|
| «КИЛЕШТЕРЕЛДЕ»:<br>Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары<br><br>_____________ Р.Р. Хәбипов<br><br>«___» ___________20___ ел | « КИЛЕШТЕРЕЛДЕ»:<br>Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары<br><br>____________ Т.Г.Таһирҗанов<br><br>«___»__________20____ ел | « КИЛЕШТЕРЕЛДЕ»:<br>Министрлыкның инвестиция сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге башлыгы<br>_____________ И.Ш. Гафуров<br><br>«___»____________20___ ел |

Мөһер урыны

**ТР _____________ мунициналь районы буенча 201___ елда авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының матди-техник базасын үстерүгә грант бирү өчен**

**ИСӘП-ХИСАП БЕЛЕШМӘСЕ № ___**

**___ ______________ 201_ ел**

| Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативыиың исеме | Эшчәнлек юнәлеше | Проектның бәясе, мең сум | Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелергә тиешле грант суммасы, мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

Кооператив житәкчесе ____________ ______________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Мөһер урыны (булса)

4 нөсхәдә тапшырыла

Яңа эш башлаучы
авыл хуҗалыгы кулланучылар
кооперативларын конкурс
буенча сайлап алуны
уздыру турында нигезләмәгә
7 нче кушымта

«Раслыйм»:
Конкурс комиссиясе рәисе

Р.Р. Хәбипов _______________
(имза)
« ___ » ______________ 20___ел

Татарстан Республикасы _____________________ муниципаль районының
______________________________________________________
(кооператив исеме)
матди-техник базасын үстерүгә

# ЧЫГЫМНАР ПЛАНЫ

| т/с № | Чыгымнар статьясы исеме | Финанслау чыганаклары, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Барысы | шул исәптән | |
| | | | грант, 90 процент | үз акча-лары |
| 1 | Авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, сатуга әзерләү буенча җитештерү объектларын төзү, реконструкцияләү яисә модернизацияләү. | | | |
| 2 | Авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продукция эшләнмәләре продуктларын әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен билгеләнгән җитештерү объектлары өчен җайланмалар һәм техника сатып алу һәм монтажлау, чыгарыла (җитештерелә, эшкәртелә) торган продукциянец сыйфатына һәм иминлегенә җитештерү контроле һәм ветеринария-санитария экспертизасы лабораторияләрен җиһазлау (авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатына лаборатор анализ ясау өчен җайланмалар сатып алу). | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | Авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын транспортировкалау һәм аларны ташыганда һәм сатканда аларның сакланышын тәэмин итү өчен махсус транспорт, фургоннар, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, контейнерлар сатып алу. | | | |
| 4 | Авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продукция эшләнмәләре продуктларын әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен җайланмалар һәм техник чаралар лизингы шартнамәләре буенча взносларның бер өлешен түләү (лизинг әйберләренең гомуми хакыннан 8 проценттан да артык булмаган күләмдә). | | | |
| | **Барысы:** | | | |

Кооператив җитәкчесе ______________ ______________________

___ ___________ 20___ ел

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме) (дата)

Мөһер урыны (булса)

Яңа эш башлаучы авыл
хуҗалыгы куллануччылар
кооперативларын конкурс
буенча сайлап алуны
уздыру турында нигезләмәгә
8 нче кушымта

Форма

**Яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы куллануччылар кооперативларының матди-техник базасын үстерүгә грант бирү турында**
**ШАРТНАМӘ**

Казан шәһәре № 20____елның ___ ______

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, алга таба «Грант бирүче» дип аталачак, бер яктан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 316 номерлы карары белән расланган Нигезләмә нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов йөзендә, һәм, икенче яктан, Устав ниггезендә эш итүче Татарстан Республикасы _______________ муниципаль районының авыл хуҗалыгы куллануччылар кооперативы “_____________________________”, ОГРН ______________, ИНН__________________, алга таба «Грант алучы» дип атлачак, алга таба бергә «Яклар» дип аталачак, конкурс уздыру йомгаклары буенча (конкурс комиссиясе утырышының 201__елның ___ _______ _____ номерлы беркетмәсе һәм Грант бирүченең бюджет акчалары бирү турында 201__елның ___ _______ _____ номерлы боерыгы) түбәндәгеләр турында әлеге шартнамәне төзеделәр:

## 1. Шартнамә предметы

1.1. Грант бирүче Грант алучыга яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы куллануччылар кооперативының матди-техник базасын үстерүгә грант бирә.

1.2. Грант алучы грантны конкурс комиссиясе тарафыннан расланган чыгымнар планы нигезендә _________________________өчен кулланырга һәм грант алган көннән 24 ай узгач еллык продукция җитештерү күләмен кимендә____________________җиткерергә йөкләмә ала.

1.3. Грант суммасы Грант бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең (алга таба – Идарә) Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлекчәсендә ачылган шәхси счетына күчерелә, ә Идарә аны Грант алучының Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлекчәсендә ачылган шәхси счетына күчерә һәм ул __________ (______________________________) сум тәшкил итә. (сүзләр белән языла)

## 2. Грант бирүченең хокуклары һәм бурычлары

2.1. Грант бирүче:

Грант алучының әлеге Шартнамә белән үзенә йөкләнгән бурычларны үтәвен тикшереп тора;

Грант алучыдан проектны гамәлгә ашыруга кагылышлы финанс һәм башка беренчел исәпкә алу документларын соратып ала;

грантның проектны гамәлгә ашыруга гына тотылышын раслау өчен Грант алучы тарафыннан тапшырылган документларны тикшерә, шулай ук проектның фактта гамәлгә ашырылуын тикшерә;

2.2. Грант алучыга, әлеге Шартнамә төзелгән мизгелдән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча, финанслау лимитлары булса, акчалар күчерү юлы белән грант суммасын түләүне гамәлгә ашыра.

2.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «ТР бюджеты акчалары исәбенә агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2018 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карарында каралган грант бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары бозылу факты (фактлары) билгеләнгән яисә алар турында дәүләт финанс контроле органыннан мәгълүмат алынган очракта, шул исәптән әлеге Грант алучы тарафыннан Шартнамә нигезендә тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләр күрсәтелгән очракта, шул хокук бозулар бетерелгәнче, грант бирү Грант бирүче тарафыннан туктатып торыла, бу хакта туктатып тору турында карар кабул ителү датасыннан 10 эш көненнән дә соңга калмыйча катгый рәвештә Грант алучыга хәбәр ителә.

## 3. Грант алучының хокуклары һәм бурычлары

3.1. Грант алучы:

3.1.1. Федераль казначылыкның территориаль органында бюджет процессында катнашмаучы операцияләрен исәпкә алу өчен счет ача;

3.1.2. Идарәгә түбәндәге документларны тапшыра:

чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алынган әйберләрнең һәркайсының хакыннан кимендә 10 процентын үз акчалары исәбеннән түләнүен раслый торган документларның Министрлык тарафыннан расланган форма буенча җыелма реестрын, күрсәтелгән документларның күчермәләрен (түләү йөкләмәләренец (поручениеләрнең), шартнамәләрнең, накладнойларның, фактура счетларының, ветеринария документларының, сатып алынган әйберләрне дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның күчермәләрен, сатып алынган әйберләрнең фотографияләрен);

максатчан чыгымнарны түләүгә түләү йөкләнешләрен, максатчан чыгымнарны түләү буенча Грант алучыда түләү йөкләмәләрен китереп чыгарган шартнамәләрне, үтәүченең (подрядчикның, поставщикның) тулы исеме, товарның (хезмәт күрсәтүләрнең) исеме, чыгымнар планы нигезендә грант чикләрендәге суммага аларның саны (күләме) күрсәтелә;

3.1.3. Грант исәбенә гамәлгә ашырыла торган операцияләрнең аерымланган аналитик исәбен алып барырга үз өстенә йөкләмә ала;

3.1.4. Нәтиҗәлелек күрсәткечләре һәм (яисә) 1.2 пунктта билгеләнгән башка күрсәткечләр зурлыгына ирешүне тәэмин итә;

3.1.5. Грантны үзләштерә башлаган көннән алып 5 ел буена Грант алучы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) «Эшчәнлек турында белешмәләр» формасы буенча нәтиҗәлелек күрсәткечләре зурлыгына ирешү турында еллык хисаплар тапшыра. Хисаплар Грант алучы тарафыннан Идарәләргә Министрлык боерыгы белән расланган формалар буенча хисап чоры узганнан соң 10 көн эчендә тапшырыла. Идарәләр хисаплар кергәннән соң 10 көн эчендә аларны килештерәләр һәм Министрлыкка җибәрәләр;

3.1.6. Грант үзләштерелә башлаган көннән 24 ай эчендә Министрлыкка гранттан максатчан файдалану турында, Идарә башлыгы белән килештерелгән, «Җыелма реестр» формасы буенча хисап тапшыра, аңа хисап документлары өстәлеп бирелә. Хисап документлары дип, законнар нигезендә шулай дип танылган документлар атала (түләүне, товарлар алуны һәм (яисә) хезмәтләр күрсәтүне раслый торган документлар, фотографияләр). Хисаплар Грант алучының имзасы һәм мөһере (булса) белән таныкланган һәм Татарстан Республикасы ______________________ муниципаль районындагы Идарә башлыгы белән килештерелгән булырга тиеш;

3.1.7. Грант акчаларын шәхси счетка акчалар кергән көннән 24 ай эчендә үзләштерә һәм бары тик яңа эш башлаган авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының матди-техник базасын үстерүгә генә тота;

3.1.8. Чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алына торган әйберләрнең, башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакыннан кимендә 10 процентын үз акчалары исәбеннән түли;

3.1.9. Грант акчаларын кулланып алган мөлкәтне авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының бүленми торган фондына кертә;

3.1.10. Грант акчаларын кулланып алган мөлкәт читләштерелгән очракта, әлеге шартнамәнең гамәлдә булу срогы узганчы бюджет акчаларын кире кайтара;

3.1.11. Грант акчаларын алганнан соң 24 айдан да соңга калмыйча һәр 2,5 млн. сум күләменә кимендә бер даими эш урыны булдыра;

3.1.12. Кооперативның җитештерелгән (эшкәртелгән) продукциясе күләмнәре үсешен әлеге шартнамәнең гамәлдә булу чорында ел саен кимендә 10 процентка артуын тәэмин итә.

3.1.13. Кооперативның үзе җитештергән авыл хуҗалыгы продукциясен җыю һәм эшкәртү өлешен, транспортировкалауны, саклауны тәэмин итү, әлеге кулланучылар кооперативы әгъзалары җитештергән авыл хуҗалыгы чималыннан кооператив үзе җитештергән продукцияне башлангыч эшкәртүне дә кертеп, шулай ук башкарылган эшләрдән (күрсәтелгән хезмәтләрдән) шул авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы әгъзалары өчен гомуми күләмдә кимендә 50 процентын тәэмин итә;

3.1.14. Грант үзләштерелгән датадан кимендә 5 ел финанс-хуҗалык эшчәнлеген, шул вакыт эчендә яңа барлыкка килгән даими эш урыннарын саклап, гамәлгә ашыра;

3.1.15. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан кооперативның грант шартларын, максатларын һәм куллану тәртибен үтәвенә тикшерүләр уздыруга ризалык бирә.

3.2. Икеяклы килешү буенча яклар, Грант алучы проект хакының чыгымнар планында күрсәтелгән кимендә 10 процентын үз акчаларыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль органында ачылган шәхси счетка бюджет процессында катнашмаучы операцияләрен исәпкә алу өчен күчерә, дип килешәләр.

3.3. Грант исәбенә алынган активлар Грант алучы исеменә теркәлергә һәм Татарстан Республикасы _________________________ муниципаль районы территориясендә кулланылырга тиеш.

3.4. Грант акчалары исәбенә сатып алынган мөлкәт кооперативның бүленми торган фондына кертелә һәм сатылмый, бүләк ителми, арендага, тапшырылмый, алмаштырылмый яисә пай, взнос рәвешендә кертелми яки башка рәвештә читләштерелми.

3.5. Кооператив авыл хуҗалыгы кооперативларының ревизия берлеге әгъзасы була һәм ел саен үз эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча Министрлыкка ревизия бәяләмәсен тапшыра.

3.6. Грант алучы тарафыннан алынган акчалар исәбенә түбәндәгеләрне башкару **тыела:**

3.6.1. Югары технологияле чит ил җайланмаларын, чимал һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (кайтарганда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук бу чараларны алу максатларына ирешүгә бәйле башка операцияләрдән тыш, чит ил валютасын алу;

3.6.2. Башка юридик затның (юридик затның иярчен җәмгыятенең) устав (җыелма) капиталына взнос буларак, башка юридик затның (юридик затның иярчен җәмгыятенең) мөлкәтенә аның устав (җыелма) капиталын арттырмаслык кертем буларак куллану, әгәр максатчан акчалар бирү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны күрсәтелгән юридик затка (юридик затның иярчен җәмгыятенә) аның Россия Федерациясе үзәк банкы учреждениесендә яисә кредит оешмасында ачылган счетларына күчерү мөмкинлеге каралмаган булса;

3.6.3. Акчаларны депозитларга салу, шулай ук башка финанс инструментларына урнаштыру максатларында куллану, әгәр федераль законнарда яисә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында башкасы билгеләнмәгән булса;

3.6.4. Грант алучыга банкта ачылган счетларга акчалар күчерү тыела, моңа түбәндәге очраклар керми:

3.6.4.1. Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә юридик затның йөкләмәләрен түләү;

3.6.4.2. Хезмәт хакына исәпләнгән суммаларны һәм социаль түләүләрне исәпкә алып, юридик затның хезмәт өчен түләү буенча йөкләмәләрен түләү, шулай ук Грант алучының штатында тормый торган, максатчан акчалар бирелгәндә билгеләнгән максатларга ирешү өчен җәлеп ителгән хезмәткәрләр файдасына башка түләүләр;

3.6.4.3. Финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан акчалар булган Грант алучы тарафыннан фактта башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр, әзерләнгән продукция өчен түләү, әгәр Грант алучы эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү һәм продукция әзерләү өчен башка юридик затларны җәлеп итмәсә, шулай ук нигези документларны һәм (яисә) килешүләрдә, дәүләт контрактларында, капитал салулар турындагы шартнамәләрдә, учреждениеләр контрактларында, субсидияләр бирү турындагы шартнамәләрдә (контрактларда, килешүләрдә) яисә норматив хокукый актларда каралган башка документларны биргәндә;

3.6.4.4. Грант алучы тарафыннан тотылган 3.6.4.3 пунктында күрсәтелгән чыгымнарны раслый торган документларны, түләү йөкләнешләре, түләү йөкләнешләре реестрлары күчермәләрен, шулай ук капитал салулар турында килешүнең, дәүләт контрактының, шартнамәнең, субсидияләр бирү турында учреждение контрактының һәм шартнамәсенең (контрактның, килешүнең) яисә башка норматив хокукый актның күчермәләрен тапшырганда (әгәр капитал салулар турында дәүләт контрактында, шартнамәсендә, учреждение контрактында һәм шартнамәсендә (контрактында, килешүендә) юридик зат тоткан чыгымнарны (чыгымнар өлешен) каплау каралган булса), Грант алучы тарафыннан тотылган чыгымнарны (чыгымнар өлешен) кайтару.

3.6.5. Юридик зат – максатчан акчалар алучы – белән төзелгән шартнамәләр (контрактлар, килешүләр), элемтә хезмәтләренә, коммуналь хезмәтләргә, электр энергиясенә, авиация һәм тимер юл билетларына, шәһәр һәм шәһәр яны транспортында йөрү өчен билетларга, матбугат басмаларына язылуга, арендалауга, юридик затларга караган инженерлык челтәрләрен, коммуникацияләрне һәм корылмаларны Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнары нигезендә күчереп урнаштыруга (яңадан төзүгә, тоташтыруга) шартнамәләрдән тыш, шулай ук иминләштерү законнары нигезендә төзелгән иминият шартнамәләре нигезендә банкларда ачылган счетларга күчерү.

3.7. Грантны куллану йомгаклары буенча Грант алучы гранттан максатчан файдалану турында «Килештерү кәгазен» Министрлыкның тармак бүлекләре, аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлеге башлыкларыннан һәм кооперативларның матди-техник базасын үстерүгә грантлар бирү өчен авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе рәисеннән имзалата.

## 4. Якларның җаваплылыгы

4.1. Яклар үз йөкләмәләре өчен законнар нигезендә җаваплы булалар. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары грант бирү

шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен һәм аннан максатчан файдалануны законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерәләр.

4.2. Бирелгән грантлар, әгәр аларны бирү тәртибе, Шартнамәнең 3.1. пунктында билгеләнгән максатлары һәм шартлары бозылу, грантлардан максатчан файдаланмау йә грант алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар бирелү фактлары ачыкланса, Министрлыкның таләбе алынган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

4.3. Грант алучы тарафыннан Министрлыкка һәм Идарәгә тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык Грант алучыга йөкләнә.

4.4. Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ихтыярый рәвештә кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә тартып алынырга тиеш.

4.5. Шартнамәне гамәлгә ашыру барышында барлыкка килергә мөмкин булган каршылыклар Яклар сөйләшүләре аша хәл ителергә тиеш. Каршылыкларны сөйләшүләр аша хәл итеп булмаган очракта, алар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителергә тиеш.

4.6. Яклар Шартнамә буенча йөкләмәләрне тулысынча яисә өлешчә үтәү өчен җаваплылыктан бары тик форс-мажор хәлләр (РФ ГК, ст. 401, п.3) барлыкка килгәндә генә азат ителәләр. Әмма мондый хәлләр барлыкка килү үзе Грант алучының үз йөкләмәсен үтәвен туктатмый, әгәр аны бу хәлләр беткәннән соң үтәп була торган булса.

4.7. Шартнамәне вакытыннан алда өзү, Якларның үзара килешүе буенча бюджет законнары нигезендә тиешле бюджетка___________сум (______________________сум) күләмендә грантны керткәч, башкарыла.

(сүзләр белән языла)

4.8. Шарнамәне Грант бирүче тарафыннан суд тәртибендә Россия Федерациясе Граждан кодексының 450 статьясы нигезендә өзү түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

1) Грант алучы тарафыннан грант үтәлеше турында хисаплар бирелмәсә яисә алар тулысынча бирелмәсә һәм Шартнамә йөкләмәләре үтәлмәсә;

2) хисап документлары тикшерелгәндә Грант бирүче тарафыннан ачыкланган белешмәләрне Грант алучы белә торып бозса;

3) грант акчаларының максатчан тотылмавы ачыкланса;

4) Грант алучы тарафыннан эшчәнлек грант алынган көннән биш ел эчендә туктатылса һәм (яисә) проектны гамәлгә ашыру буенча үзенә алынган йөкләмәләр Грант алучы тарафыннан үтәлмәсә;

5) әгәр проект Шартнамә төзелгән көннән 24 ай эчендә мөһим сәбәпләрсез (каршы тора алмаслык хәлләр, ягъни гадәттән тыш хәлләр (җир тетрәү, давыл, су басу, янгын һ.б.лар) гамәлгә ашырылмаса.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Шартнамә аны имзалаган көннән үз көченә керә һәм 20______елның

___ __________ кадәр гамәлдә була.

5.2. Шартнамәгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара килешүе буенча аңа Яклар тарафыннан имзалана торган өстәмә язма килешү төзү юлы белән кертелә.

5.3. Шартнамә тигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә төзелде, Якларның һәркайсына берәр нөсхә бирелде.

## 6. Якларның реквизитлары һәм имзалары

| **Грант бирүче:** | **Грант алучы:** |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | ______________________________ |
| | теркәлү адресы:<br>______________________________<br>______________________________ |
| 420014, Россия, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Федосеев ур., 36 йорт | урнашкан урынының адресы:<br>____________________<br>______________________________ |
| р/с 40601810322022000048 в ГРКЦ НБ РТ банка России | р/с<br>в ОТДЕЛЕНИИ-НБ РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН |
| БИК 049205001<br>УФК по РТ (Минсельхозпрод РТ – л/сч. ЛБ 007090001 Аппарата МСХиП)<br>ИНН 1654019555<br>КПП 165501001<br>ОГРН 1021602854580 | ИНН ТоДК<br>КПП ТоДК<br>БИК<br>л/сч. ____________________ БИК<br>______________________________<br>Кооператив<br>ОГРН______________________<br>Кооператив<br>ИНН________________________ |

Татарстан Республикасы Премьер министры урынбасары –
Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры

М.Г. Әхмәтов ____________________ ________________ ________________
(имза) (фамилиясе, исеме, ат.ис.) (имза)

Мөһер урыны ________ 20__ ел

Мөһер урыны (булса) ___________ 20__ ел

Яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын конкурс буенча сайлап алуны уздыру турында нигезләмәгә 9 нчы кушымта

"КИЛЕШТЕРЕЛДЕ":

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Авыл ху Авыл хуҗалыг Авыл хуҗа

_____________ /_____________/

ылар кооперативы тарафыннан товар-матди кыйммәтләр, техника сатып алуга, хезмәтләр күрсәтүгә грант акчаларын тотуны исәпкә

(фамилиясе, исеме, ат. исеме)

__ТР____________муниципаль районының _____________________ авыл җирлеге ___ __________

Грант күләме ___________мең сум Эшчәнлек юнәлеше

| №№ т/с | раслый торган документның исеме (түләү йөкләмәсе) | Документ датасы | Документ номе | Кайдан (сатучының исеме) | ар, матди кыйммәтләр, техника, хезмәт күрсәтүл | Үлчәү бер. дана/баш $м^3$, кг | Саны | млек өчен бә сум | Күләме, сум | Финанслау чыганагы (грант,җәлеп ителгән акчалар яисә үзенеке) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1. | | | | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | | | |
| 3. | | | | | | | | | | |
| 4. | | | | | | | | | | |
| 5. | | | | | | | | | | |
| 6. | | | | | | | | | | |
| | Барысы: | X | X | X | X | X | | X | | |

М.У. (булса)

Кооператив җитәкчесе _________ /фамилиясе, исеме, атасының исеме/ __________/ имза/

Яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын конкурс буенча сайлап алуны уздыру турында нигезләмәгә
10 нчы кушымта

| Чор арасы: (алдагы яртыеллыкның 10 нчы числосына кадәр) |
| --- |
| |
| |

"КИЛЕШТЕРЕЛДЕ":
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы

____________________
/___________/

**ЭШЧӘНЛЕК ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР**

ТР____________________ муниципаль районының ______________________________________ 20_ ________________кадәр

(кооператив исеме)

______________________________юнәлеше буенча

1. Җитештерү күрсәткечләре:

| Т/С № | Җитештерелгән продукция күләме (тонна/мең сум) | | Сатып алынган, эшкәртелгән авыл хуҗалыгы продукциясе исеме | Авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү күләме, тонна | | Авыл хуҗалыгы продукциясен сату күләме, тонна | | Табыш, мең сум | | Барлык чыгымнар, мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | План | Факт | | Барлыгы хисап чорында | ш.ис. хисап датасына (яртыеллык-ка) | Барлыгы хисап чорында | ш.ис. хисап датасына (яртыеллыкка) | Барлыгы хисап чорында | ш.ис. хисап датасына (яртыеллыкка) | |
| 1 | | | Сөт | | | | | | | |
| 2 | | | Ит | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | | |
| 4 | | | | | | | | | | |
| 5 | | | | | | | | | | |
| 6 | | | Барлыгы: | * | * | * | * | | | |

2. Салым салу, хезмәткәрләр саны һәм аларның хезмәт хакы:

| Т/С № | Хуҗалык хезмәткәрләре белгечлегенең исеме | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Исәнләнгән хезмәт хакы, мең сум | Салымнар, мең сум | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Барлык салымнар | шул исәптән |
| 1 | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | | | | Хисап чорына | ш.ис. хисап датасына (кварталга) | | Хезмәт хакыннан тотылган суммалар | Җир салымы | Мөлкәткә салым | Транспорт салымы |
| 3 | | | | * | * | | | | | |
| 4 | | | | | | | | | | |
| 5 | Грант алганчы хезмәткәрләр саны - ____ человек | | | | | | | | | |
| 6 | Яңа кабул ителүчеләр | | | | | | | | | |
| 7 | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| Барысы: | | | | | | | | | | |

_____

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм: Кооператив җитәкчесе ______________________________

____________________

Мөһер урыны (булса) (имза)

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы
кулланучылар кооперативларын
конкурс буенча сайлап алуны
уздыру турында нигезләмәгә
11 нче кушымта

Форма

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы**

**СЕРТИФИКАТ**

*Әлеге сертификат белән*

_______________________________________________
*(кооператив атамасы)*

_______________________________________________
*(ОГРН, кооперативның ИНН)*

*яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерүгә грантлар бирү өчен сайлап алу конкурсында ______________________________ эшчәнлеге юнәлеше буенча җиңүче дип таныла һәм _____________ күләмендә грант бирелә*

*“____” ____________20___ел*
*Бирү датасы*

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министры М.Г. Әхмәтов

**Яңа эш башлаучы
авыл хуҗалыгы
кулланучылар кооперативларын
конкурс буенча сайлап
алуны уздыру турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта**

Форма

Татарстан Республикасы
авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек министры
урынбасары, конкурс
комиссиясе рәисе
Р.Р.Хәбиповка

______________________________

______________________________
(кооператив җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, адресы)

**20____елда Татарстан Республикасы _______________ муниципаль районы ___________________яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының матди-техник базасын үстерүгә грант алу конкурсында катнашуга**

**Заявка**

______________________________________________________________________________
*(Татарстан Республикасы муниципаль районы, авыл җирлеге исеме)*

______________________________________________________________________________
*(авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының исеме)*

______________________________________________________________________________
*(авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

20____елда Татарстан Республикасы _______________ муниципаль районы ___________________яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының матди-техник базасын үстерүгә грант алу конкурсында катнашуга кертүегезне сорыйм.

Түбәндәгеләрне раслыйм:

1. Кооператив бетерү, банкротлык процессында түгел;

2. Кооператив Нигезләмәдә күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар алучы түгел;

3. Кооперативның Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне кайтару буенча түләнми калган бурычлары һәм шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты каршында башка түләнми калган бурычлары юк;

4. Кооперативның Россия Федерациясе салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк;

5. Конкурста катнашу шартлары белән таныштым һәм риза.

Документларда һәм аларның күчермәләрендә бирелгән барлык мәгълүмат дөрес һәм мин грант бирүгә документларны карауда катнашучы затларның аларны карауларына каршы түгел.

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы җитәкчесе ____________ ___________________

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

М.У. (булса)

« » __________ 20__ ел.

Приложение № 11
к Положению о проведении
конкурсного отбора начинающих
сельскохозяйственных
потребительских кооперативов

Форма

МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# СЕРТИФИКАТ

***Настоящим сертификатом удостоверяется, что***

____________________________________________________
*(Наименование кооператива)*

____________________________________________________

____________________________________________________

____________________________________________________,
*(ОГРН, ИНН кооператива)*

***является победителем конкурсного отбора для предоставления грантов на развитие материально-технической базы начинающих сельскохозяйственных потребительских кооперативов по направлению деятельности (____________________) в размере***

____________________________________________________

*Дата выдачи «__» ______________ 20__ г.*

**Заместитель Премьер-министра
Республики Татарстан -
министр сельского хозяйства
и продовольствия Республики Татарстан** **М.Г.Ахметов**